КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 октябрь г.Казань № 907

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләргә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормага салу турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларны үтәүне тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 март, 186 нчы; 2017 ел, 28 июнь, 442 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «урнаштырган көннән соң җиде календарь көненнән» сүзләрен

«хокукый актларны урнаштырган көннән соң биш эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. ТР ИСТҮ җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен һәм (яки) искәрмәләрен карап тикшергән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча бу тәкъдимнәрне һәм (яки) искәрмәләрне һәм аларга җавапларны сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштыра.»;

8 пунктта «елына кимендә бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш» сүзләрен «кирәк булганда карап тикшереләләр» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин